МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОСУДАРСТВЕННОЕ АВТОНОМНОЕ ПРОФЕССИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«КУКМОРСКИЙ АГРАРНЫЙ КОЛЛЕДЖ»

«Утверждаю»
________
Директора ГАПОУ
«Кукморский аграрный колледж»
А.Х.Гатин

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА УЧЕБНОЙ ДИСЦИПЛИНЫ

## УД.15.01 ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК И ЛИТЕРАТУРА

основной образовательной программы
по профессии среднего профессионального образования
**43.01.09 Повар, кондитер**

2017

Программа образовательной учебной дисциплины “Татарский язык и литература” предназначена для изучения татарского и языка и литературы в профессиональных образовательных организациях СПО реализующих образовательную программу среднего общего образования в пределах освоения основной профессиональной образовательной программы СПО (ОПОП СПО) на базе основного общего образования при подготовке квалифицированных рабочих, служащих и специалистов среднего звена.
Рабочая программа разработана в соответсвии с “Рекомендациями по реализации образовательной программы среднего (полного) общего образования в образовательных учреждениях начального профессионального и среднего профессионального образования в соответсвие с федеральным базисным учебным планом и примерными учебными планами для образовательных учреждений Российской Федерации, реализующих программы общего образования” (письмо Депратамента государственной политики и нормативно-правового регулирования в сфере образования Минобрнауки России от 17.03.2015 № 06.259)

Организация-разработчик:

Государственное автономное профессиональное образовательное учреждение “Кукморский аграрный колледж”

Разработчик:

Шакирова Разина Габдельбаровна - преподаватель татарского языка и литературы.

Рассмотрена на заседании цикловой методической комиссии гуманитарных и социально-экономических дисциплин

Протокол № 1 от 25 августа 2017 года.

Председатель методической комиссии ____________________ А.Э. Сулейманова

**Эчтәлек**

1. **Уку фәненең эш программасы паспорты......................................4**
2. **Уку фәненең эчтәлеге....................................................................8**
3. **Уку фәнен тормышка ашыру шартлары...................................21**
4. **Уку фәнен үзләштерүне тикшерү һәм бәяләү.............................22**

## 1. Уку фәненең эш программасы паспорты

**Татар  теле һәм әдәбияты**

**1.1.** Татар теле һәм әдәбияты эш программасы һөнәри белем бирүнең техник һәм социаль икътисад юнәлештәге 43.01.09 Повар,кондитер һөнәре һөнәри белем бирүнең төп өлеше булып тора.

**1.2. Фән төзелеше:**

Базис укыту планы белән эшләүче урта һөнәри белем бирүче “Кукмара аграр көллияте” дәүләт автоном мәгариф учреждениясендә татар теле һәм әдәбиятын укыту программасы 3 бүлектән тора: эш программасының паспорты, төп эчтәлек, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр.

**1.3. Фәннең гомуми характеристикасы:**

Программа Татарстан Республикасындагы һөнәри көллиятендә тулы булмаган урта мәктәп белеме белән килүче татар балаларына татар теле һәм әдәбияты укыту өчен төзелде. Көллияттә татар теле һәм әдәбиятына гуманитар предметлар рәтеннән беренчел дәрәҗәдәге әһәмият бирелә, укучыларның рухи дөньясын, әхлагын формалаштыруда әһәмиятле чара булып санала.

Матур әдәбиятның башка берни белән дә алыштыра алмаслык мөһим сыйфатлары бар. Анда халыкның күп гасырлар буена тупланып килгән күңел байлыгы, “энҗе – мәрҗәннәре” тупланган. Халкыбызның төрле йолалары, моңнары, сәнгате, тарихы, бәйрәмнәре,эш сөючәнлеге – барысы да әдәбиятта чагылыш таба. Матур әдәбият – шул зур байлыкның мөһим бер өлеше булып тора. Әдәбият - әдәпле итү, яшь буынга әдәплелек кануннарын бирү билгеләмәсен аңлата. Моның өчен ул төрле сүрәтләү чаралары һәм алымнардан файдалана.

Текстны үзләштерү дәверендә авторның образлы фикерләве балалар күңелендә кала. Автор язганны сөйләп чыгу укучының тел байлыгын үстерә, сүзлек запасын арттыра.

Тел дәресләрендә, сүз сәнгате буларак, әдәби әсәрне аңлау һәм кабул итү дәрәҗәсе камилләшә. Татар теле дәресләрендә рус телен, чит ил телләрен өйрәнүгә дә нигез салына. Татар теле дәресләрендә танып белү, фикерләү сәләтен үстерүгә зур игътибар бирелә. Укучыларның акыл һәм иҗади сәләтләрен үстерү тәэмин ителә, хәтерләре һәм күзаллау дәрәҗәсе яхшыра, гомуми караш даирәсе үстерелә, мөстәкыйль уку эшчәнлеге күнекмәләре формалаша. Төрле белемнәрне үзләштерү һәм саклау формасы буларак, татар теле көллияттә укытыла торган башка предметлар белән тыгыз бәйләнештә тора һәм аларны үзләштерү сыйфатына уңай тәэсир итә.

**1.4. Фәннең максаты һәм бурычлары:**

Татар әдәбиятын өйрәнү түбәндәге **максатларга** ирешүгә юнәлтелгән:

- тиз үзгәрүчән заман шартларында файдалы җитештерүчән хезмәткә яраклы, үз-үзен танып белергә һәм һәрдаим камилләштерергә әзер, рухи дөньясы бай булган шәхес тәрбияләү; гуманлылык карашлары, милли үзаң, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, әдәбиятка һәм халыкның мәдәни кыйммәтләренә ярату һәм хөрмәт булдыру;

- укучыларда әдәбиятның үзенчәлекләре турындагы карашларны, әдәби текстны кабул итү, автор позициясен аңлау. әдәби процессның тарихи һәм эстетик нигезләренә төшенү, образлы һәм аналитик фикерләү культурасын, эстетик һәм иҗади сәләтне, кызыксынуны, әдәби зәвыкны; телдән һәм язма сөйләмне үстерү;

- матур әдәбият текстларын эчтәлек һәм форма берлегендә аңлап кабул итү, төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне белү; әдәби-тарихи процесс турында гомуми караш булдыру;

- әдәби-теоретик белемнәр нигезендәәдәби әсәрне тарихи-әдәби җирлеген аңлап һәм сәнгати кыйммәте бөтен тулылыгында гына ачыкланучы буларак анализлау һәм шәрехләү; төрле типтагы сочинениеләр язу; кирәкле мәгълүматларны (Интернет челтәре аша да) табу, системалаштыру һәм файдалану күнекмәләре булдыру;

- туган әдәбиятта һәм башка халыклар әдәбиятларында чагылыш тапкан әхлакый идеалны үзара бәйләнештә аңлау һәм әдәби-сәнгати фикерләүдәге уртак һәм милли үзенчәлекләрне ачыклау.

Татар әдәбиятын укытуның **бурычлары** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- укучының татар әдәби телен үзләштерүенә, текстны аңлап, сәнгатьле итеп, йөгерек укуына, дөрес яза белүенә, әдәби тел нормаларын саклап, төрле темаларга иркен сөйләшүенә ирешү.
- укучыларны гомумән татар әдәбияты, халык авыз иҗаты, татар халкының җыр-музыкасы, театры, сынлы сәнгате белән таныштыру, күренекле яззучылар һәм аларның әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү.
- халык тарихын һәм мирасын өйрәнү аша яшүсмерләрдә Ватанга, халыкка, туган телгә мәхәббәт, олыларга, кечеләргә һәм, гомумән, кешегә ихтирам, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек тәрбияләү. Шулай ук хезмәт тәрбиясе һәм эстетик тәрбия бирү.

Бу бурычлар үзара тыгыз бәйләнгәннәр. Алар бердәм уку-укыту процессында гамәлгә ашырылалар, чөнки дәрестә белем бирү, шәхес формалаштыру бергә бәйләп алып барыла.

Программага әсәрләр киләчәк яшь буынны мәрхәмәтле, шәфкатьле, туган як табигатен саклаучы һәм яратучы, гомумкешелекнең уңай сыйфатларына ия булган, милләт мәнфәгатьләрен яклардай кеше итеп тәрбияләү бурычларын күз алдында тотып сайланды.

I һәм II курсларда бирелә торган белем, осталык һәм күнекмәләрнең күләме җәмгыятебезнең иҗтимагый функцияләренә туры китереп билгеләнә. Төп идеясе - укытуның фәнни һәм гамәли нигездә оештырылуы, телне тирән белү, туган тел ярдәмендә үзара иркен аңлашу, уй-фикерләреңне һәм хис – тойгыларыңны дөрес һәм төгәл итеп белдерү.

Татар телен өйрәнүнең максатлары һәм бурычлары:

- укучыларның сүзлек байлыгын арттыру, сөйләм һәм язма телен үстерү белән беррәттән, рухи дөньясын баету, реаль чынбарлыкка дөрес караш формалаштыру, тормыш вакыйгаларына хәбәрдарлыгын тәэмин итү;
- татар теленнән алынган теоретик материалны (тел системасын) аңлап үзләштерүне һәм тел фәнен яхшы белүне тәэмин итү; гамәли тел материалларын хәтердә калдырып һәм тәрбияви максатны күздә тоткан хәлдә, әдәбият дәресләре программасында бирелгән текстларны анализлый белү, изложение һәм сочинениеләрне логик фикерләп, телдәге сурәтләү чараларын дөрес һәм урынлы кулланып, грамоталы итеп һәм дөрес каллиграфия белән яза белүләренә ирешү, идея дәрәҗәсенең югары булуын тәэмин итү, текст өстендә эшләү күнекмәләрен камилләштерү, үзеңнең һәм иптәшләреңнең кылган гамәлләренә дөрес бәя бирү, информация чыганакларыннан кирәкле мәгълүматларны таба һәм куллана белергә өйрәтү;
- укучыларда дәреслек һәм өстәмә әдәбияттан (әдәби әсәрләре, фәнни чыганаклар, төрле сүзлекләр, вакытлы матбугат) дөрес файдалану күнекмәләрен үстерү, план, тезис, конспектлар төзү, эш кәгазьләрен (деловые бумаги) дөрес һәм грамоталы язарга өйрәтү;
- бәйләнешле сөйләм культурасын үстерү өчен, укучыларда укыганны һәм сөйләгәнне кабул итү, сөйләмнән урынлы файдалану осталыгын (уку,язу,сөйләү,тыңлау, аңлау, сөйләшү, аралашу, диалогик һәм монологик сөйләм) иҗади эш башкару күнекмәләрен формалаштыру һәм үстерү.

### 1.5. Белем дәрәҗәсе таләпләре:

**Укучыларның үзләштерергә тиешле белем – күнекмәләре:**

Татар әдәбиятының дөнья күләм тоткан урыны, татар әдәбияты классиклары, аларның әсәрләре турында мәгълүмат; сүз сәнгатенең образлы табигате турында; әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп факторы; төп әдәби – теоретик төшенчәләр; халык авыз иҗаты һәм әдәбият; татар әдәбияты тарихын чорларга бүлә белү; әдәби әсәрләрнең эчтәлеген һәм төзелешен (тема, идея, сюжет, композиция, образлар системасы һ.б.) анализлый белү; матур темадагы мәңгелек темалар, әдәбиятнын башка сәнгать төрләре белән бәйләнеше;фонетика, лексика тармаклары турында, сузыкларга һәм тартыкларга хас орфоэпик һәм орфографик нормаларны белү, аваз үзгәрешләренә аңлатма бирә белү; татар теленең сүзлек составын белү,лексикография буенча тулы мәгълүмат бирә белү; сүз төзелеше, сүз ясалышы, кушымчалар турындагы белемнәрне ныгыту; сүз төркемнәре, синтаксис буенча тулы мәгълүмат алу, язу тарихын тирән белү.

### Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:

1. Орфография, орфоэпия нормаларын үзләштерү, фонетик анализ ясый белү.
2. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.
3. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау
4. Сүзләргә фонетик, морфологик, синтаксик анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру, анализ үрнәкләрен камил белү.
5. Сүз ясалышын, төзелешен, сүзтезмәләрне тикшерү үрнәкләрен камил белү.
6. Орфографик прициплар һәм аларның нормаларын белү.

7. Стилистика һәм сөйләм культурасы нормаларын төгәл белү.
8. Пунктуация кагыйдәләреннән дөрес файдалану.
9. Сөйләм эшчәнлеге буенча тулы мәгълүматлы булу.
10.Текстның исеме, андагы таныш исемнәр ярдәмендә укучыларның эчтәлекне аңлаулары, укылган текст буенча әңгәмәдә катнаша алу.
11.Өйрәнелгән язучылар турында сөйли белү.
12. Укылган текстның эчтәлеген сөйли һәм нәтиҗә ясый белү, аңа үз мөнәсәбәтеңне белдерә алу.
13. Уку һәм сөйләм барышында орфоэпик нормаларны саклау.
14.Балалар өчен басылган вакытлы матбугат материалларын уку һәм файдалана алу.

## 1.6. Фәнне үзләштерү өчен сәгатьләр саны:

- максималь уку йөкләнеше: 198 сәгать;
- шул исәптән мәҗбүри аудитор уку йөкләнеше: 126 сәгать;

## 1.7. Укыту фәненең күләме һәм укыту төрләре

| **Укыту төрләре** | ***Сәгатьләр саны*** |
|---|---|
| **Максималь эш күләме (барлыгы)** | *198* |
| **Мәҗбүри эш күләме (барлыгы)** | *126* |
| шул исәптән: | |
| Практик эшләр | *54* |
| Контроль эш | |
| *Аттестация: имтихан* | *6* |

## 2.Уку программасынның эчтәлеге

| Бүлекләр һәм темалар исемлеге | Укыту материалының эчтәлеге, практик эш, укучыларның үзлектән эше | Үткәрелгән вакыты (сәг.) | Үзләш. дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **1 нче бүлек** | **Тел – аралашу чарасы, иҗтимагый һәм сәяси күренеш** | **4** | |
| Тема 1.1. | Телнең төп функцияләре. Туган тел. Төрки телләр. Татар теле белеменең төп тармаклары. Тел һәм сөйләм. Сөйләм үзенчәлекләре. Монологик һәм диалогик сөйләм. Интонация. Сүзне оштыручы иҗек басымы. | 2 | III |
| | **Практик эш:** Телгә карата күнегүләр | 1 | |
| | **Тикшерү эше:** Кереш тикшерүе. | 1 | |
| **2 нче бүлек** | **Фонетика. Орфоэпия. Графика. Аваз. Фонема.** | **3** | |
| Тема 2.1. | Аваз һәм хәреф. Транскрипция. Сузык һәм тартык авазлар. Аваз үзгәрешләре. Орфоэпия, графика, орфография. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Фонетикага, орфоэпиягә, графикага, аваз һәм фонемаларга күнегүләр | 1 | |
| **3 нче бүлек** | **Язу тарихы** | **3** | |
| Тема 3.1. | Рун язуы. Гарәп язуы. Латин графикасы. Кирилица. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Күнегүләр өстендә эш | 1 | |
| **4нче бүлек** | **Лексика** | **4** | |
| Тема 4.1. | Синонимнар. Антонимнар. Күп мәгънәле сүзләр. Омонимнар. Фразеология. Татар теленең сүзлек составы. | 2 | III |
| | **Практик эш:** Синонимнар, антонимнар, күп мәгънәле сүзләр, омонимнар, фразеологизмнар өстендә эш. | 1 | |
| | **Тикшерү эше:** Рефератлар яклау | 1 | |
| **5 нче бүлек** | **Морфология** | | |
| Тема 5.1. | **Исем** | **3** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Исемнәрнең берлек һәм күплек саны. Исемнәрнең килеш белән төрләнүе. Изафә бәйләнеше. Исемнең тартым белән төрләнүе. Исемнәрнең ясалышы. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Исемнәр кергән күнекмәләр өстендә эш. | 1 | |
| Тема 5.2. | **Сыйфат** | **3** | |
| | Сыйфат. Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатларның ясалышы ягыннан төрләре. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Сыйфатлар кергән күнекмәләр өстендә эш. | 1 | |
| Тема 5.3. | **Сан** | **2** | |
| | Сан. Сан төркемчәләре. | 1 | II |
| | **Практик эш:** Саннар кергән күнекмәләр өстендә эш. | 1 | |
| Тема 5.4. | **Алмашлык** | **2** | |
| | Алмашлык төркемчәләре. | 1 | II |
| | **Практик эш: :** Алмашлык кергән күнекмәләр өстендә эш. | 1 | |
| Тема 5.5. | **Фигыль** | **8** | |
| | Фигыльгә хас морфологик категорияләр. Фигыльгә хас лексик – грамматик категорияләр. Фигыльдә сан категориясе. Раслау һәм инкяр. Фигыль төркемчәләре. Фигыль юнәлешләре. Фигыльнең ясалышы ягыннан төрләре. Фигыль формаларында басым. | 4 | III |
| | **Практик эш:** Фигыльләр кергән күнекмәләр өстендә эш. | 2 | |
| | **Тикшерү эше:** Изложение яздыру. | 2 | |
| Тема 5.6. | **Рәвеш** | **2** | |
| | Рәвеш. Рәвеш төркемчәләре. | 1 | II |
| | **Практик эш:** Рәвеш кергән күнекмәләр өстендә эш. | 1 | |
| | **Ярдәмлекләр** | **3** | |
| Тема 5.7. | Теркәгечләр. Бәйлекләр. Бәйлек сүзләр. Кисәкчәләр. | 2 | III |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Ымлыклар. | | |
| | **Практик эш:** Ярдәмлекләр кергән күнекмәләр өстендә эш. | 1 | |
| **6 нче бүлек** | **Йомгаклау** | **1** | |
| Тема 6.1. | **Тикшерү эше:** Тестлар буенча эш. | 1 | III |
| **7 нче бүлек** | **Синтаксис** | **3** | |
| Тема 7.1. | Татар теле турында гомуми мәгълүмат. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар. Ияртүле бәйләнешне белдерүче чаралар. Сүзтезмә һәм тезмә сүз. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Сүзтезмә кергән күнекмәләр өстендә эш. | 1 | |
| **8 нче бүлек** | **Гади җөмлә** | **7** | |
| Тема 8.1. | Җөмлә. Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләнең иярчен кисәкләре. Җөмләнең модаль кисәкләре. Тулы һәм ким җөмләләр. Раслау һәм инкяр җөмләләр. Гади һәм кушма җөмлә. Бер һәм ике составлы җөмләләр. Сүз җөмләләр. Атау җөмләгә охшаш төзелмәләр. | 4 | III |
| | **Практик эш:** Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләренә карата күнекмәләр өстендә эш. Җөмләнең модаль кисәкләренә карата күнекмәләр өстендә эш. Җөмлә төрләрен аера белү. | 2 | |
| | **Тикшерү эше:** Диктант | 1 | |
| **9 нче бүлек** | **Җөмләдә сүз тәртибе** | **2** | |
| Тема 9.1. | Сүзләрнең кире тәртибе. Җөмлә кисәкләренең кире тәртибе. Җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше һәм сүз тәртибе. Җөмләдә сүз тәртибе һәм логик басым. | 1 | II |
| | **Практик эш:** Җөмләдә сүз тәртибе | 1 | |
| **10 бүлек** | **Йомгаклау** | **1** | |
| Тема 10.1 | **Тикшерү эше:** Тестлар буенча эш. | 1 | |
| **11 нче бүлек** | **Кереш. Урта гасыр татар әдәбияты.** | **1** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Тема 11.1. | Татар әдәбияты тарихының чорларга бүленеше. | 1 | II |
| **12 нче бүлек** | **Болгар чоры әдәбияты** | **3** | |
| Тема 12.1. | Болгар чоры (XIII – XV гасыр әдәбияты, мәдәнияты). Кол Гали иҗаты. К.Галиның ”Кыйссаи Йосыф” поэмасы. | 2 | II |
| | **Практик эш:** К.Галиның ”Кыйссаи Йосыф” поэмасын анализлау. | 1 | |
| **13 нче бүлек** | **Алтын Урда чоры әдәбияты** | **3** | |
| Тема 13.1. | Алтын Урда тарихы һәм мәдәнияте. | 3 | II |
| **14 нче бүлек** | **Казан ханлыгы чоры**. | **3** | |
| Тема 14.1. | Казан ханлыгы чоры. | 3 | II |
| **15 нче бүлек** | **XVII гасыр әдәбияты.** | **2** | |
| Тема 15.1. | XVII йөз әдәбияты. | 2 | II |
| **16 нчы бүлек** | **XVIII гасыр әдәбияты.** | **5** | |
| Тема 16.1. | XVIII йөз әдәбияты. | 1 | III |
| Тема 16.2. | Утыз Имәни иҗаты һәм тормыш юлы. | 2 | |
| | **Практик эш:** “Хатыны Хәмидәгә мәрсия”, “Гыйлемнең өстенлеге турында” шигырьләрен анализлау. | 1 | |
| | **Тикшерү эше:** Язма эш. | 1 | |
| **17 нче бүлек** | **XIX гасыр әдәбияты.** | **10** | **III** |
| Тема 17.1. | Тарихи – мәдәни күзәтү. Бу чорда иҗат иткән әдипләр. | 2 | I |
| Тема 17.2. | Г. Кандалый иҗаты һәм тормыш юлы. Хатын – кыз гүзәллеген тасвирлау | 2 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Тема 17.3. | К.Насыйри иҗаты һәм тормыш юлы. | 2 | II |
| Тема 17.4. | М.Акъегетзадә иҗаты һәм тормыш юлы. М.Акъегетзадәнең “Хисаметдин менла”романы. | 2 | II |
| Тема 17.5. | З.Бигиев иҗаты һәм тормыш юлы. З.Бигиевнең “Меңнәр,  яки гүзәл кыз Хәдичә” романы. | 2 | III |
| **18 нче бүлек** | **XX гасыр башы әдәбияты** | **23** | **III** |
| Тема 18.1.<br>Тема 18.2. | Тарихи – мәдәни күзәтү. Проза. Поэзия. Драматургия. | 2 | II |
| | Г.Исхакыйның тормыш юлы. Иҗат үзенчәлекләре. | 2 | |
| | Г.Исхакыйның  “Ул әле өйләнмәгән иде” әсәре. | | |
| | **Практик эш:**  “Ул әле өйләнмәгән иде”әсәрен анализлау. | 1 | |
| Тема 18.3. | Г.Тукайның тормыш юлы.  Г.Тукай иҗатыннан үрнәкләр. | 2 | III |
| | **Практик эш:** Г. Тукай шигырьләрен анализлау. | 2 | |
| Тема 18.4. | Дәрдемәнднең тормыш юлы һәм иҗаты. Дәрдемәнднең “Кояшның нурлары” әсәре. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Дәрдемәнд шигырьләрен анализлау. | 1 | |
| Тема 18.5. | С.Рәмиевнең  тормыш юлы һәм иҗаты. | 2 | II |
| Тема 18.6. | Г.Камалның тормыш юлы һәм иҗаты. Г.Камалның “Беренче театр” комедиясе. | 3 | II |
| Тема 18.7. | Ф.Әмирханның тормыш юлы һәм иҗаты. Ф.Әмирханның “Хәят” повесте. | 2 | III |
| | **Практик эш:**  Ф.Әмирханның “Хәят” повестен анализлау. | 1 | |
| Тема 18.8. | М.Фәйзи иҗаты һәм тормыш юлы. М.Фәйзинең “Галиябану” драмасы. | 2 | II |
| | **Практик эш:**  Образларга характеристика бирү. | 1 | |
| **19 нче бүлек** | **20 нче еллар әдәбияты** | **10** | |
| Тема 19.1. | 20  нче еллар әдәбиятына күзәтү. Г.Ибраһимовның тормыш | 2 | II |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | юлы һәм иҗаты. “Казакъ кызы” романы. Өзекләр уку. | | |
| | **Практик эш:** Образларга характеристика. | 1 | |
| Тема 19.2. | К.Тинчуринның тормыш юлы һәм иҗаты. “Сүнгән йолдызлар” драмасы. Сугыш аркасында килеп чыккан трагедик вакыйгалар. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Образларга характеристика. | 1 | |
| Тема 19.3. | Һади Такташның тормыш юлы һәм иҗаты. “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасы. Мәхәбәткә бәйле шәхеснең җаваплылыгы мәсьәләсе. Поэманың актуальлеге. | 2 | III |
| | **Практик эш:** “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасын анализлау. | 1 | |
| | **Тикшерү эше:** Тестлар белән эш. Язма эш. | 1 | |
| **20 нче бүлек** | **30 нчы еллар әдәбияты** | **5** | |
| Тема 20.1. | Гадел Кутуйның тормыш юлы. Иҗат үзенчәлекләре. Г.Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар” повесте. | 2 | III |
| | **Практик эш:** “Тапшырылмаган хатлар” повестен анализлау. | 1 | |
| | **Тикшерү эше:** Язма эш: “Нәрсә ул – гаилә?” | 2 | |
| **21 нче бүлек** | **40 -50 нче еллар әдәбияты.** | **8** | |
| Тема 21.1. | Әдәбиятта Бөек Ватан сугышының чагылышы. Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты. “Моабит дәфтәрләре” циклы. Әдәбиятта, сәнгатьтә Җәлил образы. | 4 | II |
| | **Практик эш:** М.Җәлилнең шигырьләрен анализлау. | 1 | II |
| Тема 21.2. | Фатих Кәримнең тормышы һәм иҗаты. Ф.Кәримнең “Разведчик язмалары” повесте. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Лирик геройга характеристика бирү | 1 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **22 нче бүлек** | **1960 – 2000 еллар поэзиясе** | **24** | |
| Тема 22.1. | 1960 – 2000 нче еллар әдәбиятына күзәтү. 1960 – 2000 еллар поэзиясе. Г.Афзалның тормышы һәм иҗаты. | 3 | II |
| | **Практик эш:** Лирик шигырьләре. Сатирик әсәрләрендә җәмгыятьтәге һәм кешеләр характерындагы кимчелекләрне, ямьсез күренешләрне тәнкыйтьләве. | 1 | |
| Тема 22.2. | Зөлфәтнең тормыш юлы һәм иҗаты. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Зөлфәтнең “Тылсым”, “Дүрт җыр” шигырьләрен анализлау. | 1 | |
| Тема 22.3. | Ренат Харисның тормыш юлы һәм иҗаты. Р.Харис иҗатына күзәтү. | 2 | |
| | **Практик эш:** Р.Харисның “Кеше кайчан матур?” шигырен анализлау. | 1 | |
| Тема 22.4. | Хәсән Туфанның тормыш юлы. Х.Туфанның иҗатына белешмә. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Хәсән Туфанның шигырьләрен анализлау. | 1 | |
| Тема 22.5. | Сибгат Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗаты. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Сибгат Хәким шигырьләрен анализлау. | 1 | |
| Тема 22.6. | Равил Фәйзуллинның тормыш юлы һәм иҗаты. | 2 | II |
| Тема 22.7. | Р.Гаташның тормыш юлы һәм иҗаты. “Ирләр булыйк” шигыре. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Р.Гаташның иҗатын анализлау. | 1 | |
| Тема 22.8. | Кукмара төбәгендә яшәп иҗат итүче шагыйрьләр һәм шагыйрәләр. | 2 | III |
| | **Тикшерү эше:** Тестлар белән эш. | 1 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **23 нче бүлек** | **1960 – 2000 еллар прозасы** | **19** | |
| Тема 23.1. | 1960 – 2000 еллар прозасы. Фатих Хөснинең тормыш юлы һәм иҗаты. “Утызынчы ел” романы. | 2 | II |
| | **Практик эш:** “Утызынчы ел” романын анализлау. Образларга характеристика. | 1 | |
| Тема 23.2. | Ибраһим Газиның тормыш юлы һәм иҗаты. И.Газиның “Онытылмас еллар” әсәре. | 2 | II |
| | **Практик эш:** И.Газиның “Онытылмас еллар” әсәрен анализлау. | 1 | |
| Тема 23.3. | Әмирхан Еникинең тормыш юлы һәм иҗаты. Ә.Еникинең “Әйтелмәгән васыять” хикәясе. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Ә.Еникинең “Әйтелмәгән васыять” хикәясен анализлау. | 1 | |
| Тема 23.4. | Мөхәммәт Мәһдиевның тормыш юлы һәм иҗаты. М.Мәһдиевның “Бәхилләшү ” повесте. | 3 | II |
| | **Практик эш:** Язучының соңгы әсәре, нәтиҗә ясавы. Аның идея, эстетик үзенчәлекләре. | 1 | |
| Тема 23.5. | Мөсәгыйт Хәбибуллинның томыш юлы һәм иҗаты. М.Хәбибуллинның “Атилла” романы. | 3 | II |
| | **Практик эш:** Образларга характеристика. | 1 | |
| | **Тикшерү эше:** Рефератлар яклау. Тестлар белән эш. | 1 | |
| **24 нче бүлек** | **1960 – 2000 еллар драматургиясе.** | **7** | |
| Тема 24.1. | 1960 – 2000 еллар драматургиясе. Х.Вахитның тормышы һәм иҗаты. “Беренче мәхәббәт” драмасы. Әсәрдә җитди әхлакый һәм иҗтимагый мәсьәләләр яктыртылуы. | 3 | II |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Практик эш:** “Беренче мәхәббәт” драмасын анализлау. | 1 | |
| Тема 24.2. | Т.Миңнуллинның тормышы һәм иҗаты. “Үзебез сайлаган язмыш” пьесасы. Мәктәп һәм укытучылар тормышын сүрәтләү. | 3 | III |
| | **Тикшерү эше:** Тестлар белән эш. | 1 | |
| **25 нче бүлек** | **Балалар әдәбияты** | **6** | |
| Тема 25.1. | Балалар әдәбияты. Җ.Тәрҗеманов, Җәүдәт Дәрзаман һәм Шәүкәт Галиев иҗаты. | 2 | II |
| | **Практик эш:** Балалар әдәбиятында халык авыз иҗаты әсәрләре. | 1 | |
| Тема 25.2. | Роберт Миңнуллинның тормыш юлы һәм иҗаты. | 2 | III |
| | **Тикшерү эше:** Тестлар белән эш | 1 | |
| | **Йомгаклау** | **1** | |
| | **Консультация** | **12** | |
| | **Аттестация** | **6** | |
| | **Барлыгы:** | **198** | |

## 4. Уку фәнен тормышка ашыру  шартлары

**4.1. Минималь материаль – техник  тәэминителешкә таләпләр.**

Фән программасы тормышка ашыру кабинет булуны таләп итә: татар теле һәм әдәбияты кабинеты.

Уку кабинетының җаһазлары:  язу тактасы, кием шкафы, китап шкафы, өстәл (укучылар өчен), өстәл  (укытучылар өчен), урындыклар.

**4.2.Укытуның информацион тәэмин ителеше**

**Төп чыганаклар:**

1. Татар теле һәм әдәбияты — Википедия ru.wikipedia.org›wiki/Татар теле
2. Казан шәһәре администрациясенең рәсми сайты Week-end в Казани. tatarlar.ru›rubriki/tatresources.html
3. Мин татарча сөйләшәм www.proshkolu.ru
4. Tatar.com.ru: татар теле

**Өстәмә:**

Стенгазеталар һәм плакатлар; алышына торган җиһаз һәм күргәзмә әсбаплары; язучыларның портреты; тарихи китаплар. Русско –Татарский словарь, Ф.А.Ганиев, Ф.Ф.Гаффарова , Казань Татарское книжное издательство; Татарча – русча  уку – укыту сүзлеге , Ф.А.Ганиев, И.А.Абдуллин, Мәскәү “Рус теле”; “Изложенияләр җыентыгы” З.Н.Хәбибуллина, И.Г.Гыйләҗев; “Ул дәрья да бу дәрья” И.К.Хәйруллин, Р.М.Миннуллин; ”Әдәбият укыту мәсьәләләре” Л.К.Хөснетдинова; “Рус мәктәбендә татар балаларына әдәбият укыту” Ә.М.Закирзянов;  “Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы” Д.Ф.Заһидуллина. Таблицалар һәм плакатлар; алышына торган җиһаз һәм күргәзмә әсбаплары; Русско –Татарский словарь, Ф.А.Ганиев, Ф.Ф.Гаффарова , Казань Татарское книжное издательство; Татарча – русча  уку – укыту сүзлеге , Ф.А.Ганиев, И.А.Абдуллин, Мәскәү “Рус теле”;  “Диктантлар җыентыгы” Ш.Р.Сайкин; “Хәзерге татар әдәби теле” Ф.С.Сафуллина, М.З.Зәкиев; “Башлангыч мәктәптә татар теле укыту методикасы”  С.Г.Вагыйзов, Р.Г.Вәлитова;  “Татар теленең орфографик – орфоэпик сүзлеге”  Х.Сәлимов; “Морфология”                              М.М. Нигъмәтуллов. “Татар лексикологиясе” Х.Сәлим; “Татар теле” Ч.М.Харисова.

**5.Фәнне үзләштерүнең нәтиҗәсен тикшерү һәм бәяләү**

| Укыту нәтиҗәсе<br>( белергә, эшләргә тиеш) | Уку нәтиҗәләрен тикшерү һәм бәяләү формалары һәм алымнары |
|---|---|
| 1. Фонетика, лексика тармаклары турында, сузыкларга һәм тартыкларга хас орфоэпик һәм орфографик нормаларны белү, аваз үзгәрешләренә аңлатма бирә белү.<br>2. Татар теленең сүзлек составын белү. Лексикография буенча тулы мәгълүмат бирә белү.<br>3. Сүз төзелеше, сүз ясалышы, кушымчалар турындагы белемнәрне ныгыту.<br>4. Сүз төркемнәре. Синтаксис буенча тулы мәгълүмат алу.<br>5. Язу тарихын тирән белү.<br>**Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:**<br>1. Орфография, орфоэпия нормаларын үзләштерү, фонетик анализ ясый белү.<br>2. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.<br>3. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау<br>4. Сүзләргә фонетик, морфологик, синтаксик анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру, анализ үрнәкләрен камил белү.<br>5. Сүз ясалышын, төзелешен, сүзтезмәләрне тикшерү үрнәкләрен камил белү.<br>6. Орфографик прициплар һәм аларның нормаларын белү.<br>7. Стилистика һәм сөйләм культурасы нормаларын төгәл белү.<br>8. Пунктуация кагыйдәләреннән дөрес файдалану.<br>9. Сөйләм эшчәнлеге буенча тулы мәгълүматлы булу. | Изложение; диктант; тестлар; реферат; сорауларга җавап бирү; күнегүләр эшләү; конспектлар төзү. |

| | |
|---|---|
| **Укучыларның үзләштерергә тиешле белем – күнекмәләре:**<br>татар әдәбиятының дөнья күләм тоткан урыны, татар әдәбияты классиклары, аларның әсәрләре ту рында мәгълүмат; сүз сәнгатенең образлы табигате турында;<br>әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп факторы; төп әдәби – теоретик төшенчәләр; халык авыз иҗаты һәм әдәбият; татар әдәбияты тарихын чорларга бүлә белү; әдәби әсәрләрнең эчтәлеген һәм төзелешен (тема, идея, сюжет, композиция, образлар системасы һ.б.) анализлый белү; матур әдәбияттагы мәңгелек темалар, әдәбиятның башка сәнгать төрләре белән бәйләнеше.<br>**Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:**<br>Текстның исеме, андагы таныш исемнәр ярдәмендә укучыларның эчтәлекне аңлаулары; укылган текст буенча әңгәмәдә катнаша алу; өйрәнелгән язучылар турында сөйли белү;<br>укылган текстның эчтәлеген сөйли һәм нәтиҗә ясый белү, аңа үз мөнәсәбәтеңне белдерә алу; уку һәм сөйләм барышында орфоэпик нормаларны саклау;<br>балалар өчен басылган вакытлы матбугат материалларын уку һәм файдалана алу. | Изложение; инша; тестлар; реферат; эчтәлеген сөйләү; сорауларга җавап бирү; конспектлар төзү. |

## Кулланылган әдәбият.

**Төп чыганаклар (студентлар өчен):**


1. “Татар әдәбияты” дәреслек - хрестоматия, 10 кл., Миңнегулов Х.Й., Гыймадиева Н.С. , Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2006 ел.
2. “Татар әдәбияты” дәреслек - хрестоматия, 11 кл., Ф.М.Мусин, З.Н.Хабибуллина, Ә.М.Закирҗанов, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2006 ел.
4. “Татар теле” дәреслек, 10 кл., Р.С.Абдуллина, Г.М.Шәйхиева, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2006 ел.
5. “Татар теле” дәреслек, 11 кл., Ф.С.Сафиуллина, С.М.Ибраһимов Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2006 ел.


**Төп чыганаклар (укытучы өчен):**


1. Федеральный закон от 29.12.2012 № 273-ФЗ (ред.от30.12.2015) «Об образовании в Российской Федерации»
2. «Татарстан Республикасы дәүләт теллере һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004 ел. 1 июль).
3. Татар теленнән белем бирүнең дәүләт стандарты. – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлывгы. – Казан.2008
4. Абдуллина Р.С., Шайхиева Г.М. Татарский язык. Учебное пособие для 10 класса для учащихся татар). – Казань: Татар.кн.изд-во., 2012.-212 с.
5. Сборник правил по татарскому языку для русскоязычных учащихся. Казань. Издательство «Гыйлем». 2008


**Өстәмә:**


1. “Әдәбият” дәреслек, 10 кл., А.Г.Әхмәдуллин, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2005 ел
2.“Әдәбияттан хрестоматия” , 10 кл., А.Г.Әхмәдуллин, Казан. Татарстан китап нәшрияте, 2005 ел.
3. “Әдәбият” дәреслек, 11 кл., А.Г.Әхмәдуллин, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2005 ел
4. “Әдәбияттан хрестоматия” , 11 кл., А.Г.Әхмәдуллин, Казан. Татарстан китап нәшрияте, 2005 ел.
5. “Әдәбият белеме сүзлеге”, А.Г.Әхмәдуллин, Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1990 ел.
6. “Татар лексикологиясе”, Х.Сәлим.
7. “Сүзьясалышы”, М.М. Нигъмәтуллов, И.Ш.Ишмөхәммәтов.
8. “Морфология” М.М. Нигъмәтуллов.
9. “Хәзерге татар әдәби теле” Д.Г.Тумашева, Казан Университеты нәшрияты, 1978 нче ел.

10. Сафиуллина Ф.С., М.З. Зәкиев Хәзерге татар әдәби теле. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2002 нче ел.
11. “Сочинение язарга өйрәнәбез” З.Н.Хәбибуллина, Р.В.Миңнуллина, Казан, “Яңалиф” нәшрияты, 2002 нче ел.
12. Татар синтаксисы, М.З.Зәкиев, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2005 нче ел.
13. “Татар теленнән диктантлар һәм изложениеләр җыентыгы”, Н.В.Максимов, С.М.Трофимова, М.З.Хәмидуллина, Казан “Мәгәриф” нәшрияты, 2005 нче ел.

**Интернет-ресурслар:**

http://belem.ru
http://suzlek.ru
http://kitap.ru
http://gabdullatukay.ru
http://www/tugan-tel.com/
http://www.tatknigafund.ru

Прошнуровано, пронумеровано и
скреплено печатью:
21 (двадцать один) листа(ов)
Директор ГАПОУ «Кукморский аграрный
колледж»__________ А.Х. Гатин
«28» августа 2017 г.

Прошнуровано, пронумеровано и
скреплено печатью:
21 (двадцать один) листа(ов)
Директор ГАПОУ «Кукморский аграрный
колледж» ________________ А.Х. Гатин
«28» августа 2017 г.

Прошнуровано, пронумеровано и
скреплено печатью:
21 (двадцать один) листа(ов)
Директор ГАПОУ «Кукморский аграрный
колледж» ________________ А.Х. Гатин
«28» августа 2017 г.

Прошнуровано, пронумеровано и
скреплено печатью:
21 (двадцать один) листа(ов)
Директор ГАПОУ «Кукморский аграрный
колледж» __________ А.Х. Гатин
«28» августа 2017 г.

Прошнуровано, пронумеровано и
скреплено печатью:
21 (двадцать один) листа(ов)
Директор ГАПОУ «Кукморский аграрный
колледж»__________ А.Х. Гатин
«28» августа 2017 г.

Прошнуровано, пронумеровано и
скреплено печатью:
21 (двадцать один) листа(ов)
Директор ГАПОУ «Кукморский аграрный
колледж» ________ А.Х. Гатин
«28» августа 2017 г.

Прошнуровано, пронумеровано и
скреплено печатью:
21 (двадцать один) листа(ов)
Директор ГАПОУ «Кукморский аграрный
колледж» ________ А.Х. Гатин
«28» августа 2017 г.